ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 7 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү, индивидуаль гараж яисә индивидуаль торак төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;»;

2) 32 статьяның 3 пунктындагы 1 пунктчасында «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) $32^1$ статьяда:
а) 2 пунктта «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 8 пунктның беренче абзацында «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 9 пунктның беренче абзацында «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 10 пунктның беренче абзацында «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 11 пунктның беренче абзацында «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 12 пунктта «, дача төзелешен» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 34 статьяда:

а) 1 пунктның 2 пунктчасында «, терлекчелек һәм дача төзелеше» сүзләрен «һәм терлекчелек» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктның 2 пунктчасында «, терлекчелек һәм дача төзелеше» сүзләрен «һәм терлекчелек» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның «е» пунктчасындагы икенче абзацында «дачаларны,» сүзен төшереп калдырырга;

2) 15 статьяның 2 өлешендә:

а) икенче абзацта «дачалар» сүзен «бакча йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «, гараж һәм дача кулланучылар» сүзләрен «һәм гараж» сүзләренә алмаштырырга;

3) 20 статьяның 1 өлешендә «, гараж һәм дача кулланучылар» сүзләрен «һәм гараж» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 98 статьясындагы $14^1$ өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54

(I өлеш) «Гражданнарның су саклау зоналары чикләрендә урнашкан һәм агып төшүче суларны чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган бакчачылык, яшелчәчелек яисә коммерциягә карамаган дача берләшмәләре» сүзләрен «Су саклау зоналары чикләрендә урнашкан һәм агып төшүче суларны чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 6 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территорияләре.».

**5 статья**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 6 пунктындагы «а» пунктчасында «дачаларны,» сүзен төшереп калдырырга;

2) 11 статьяның 2 өлешендә:

а) 1 пунктта «дачалар» сүзен «бакча йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «, гараж һәм дача кулланучылар» сүзләрен «һәм гараж» сүзләренә алмаштырырга;

3) 15 статьяның 2 өлешендә «, гараж һәм дача кулланучылар» сүзләрен «һәм гараж» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәтне Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә сатып алу тәртибен раслау, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышын уздыру турында хәбәр урнаштырылырга мөмкин

булган массакүләм мәгълүмат чараларын билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла дип билгеләргә.

**7 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 22 декабрь
№ 114-ТРЗ